СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2022 ел №56

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Карадуган авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы №101 нче карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын җирлек башкарма комитетының җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хәбәрнамәсе нигезендә түләүне өч ай эчендә башкарырга .

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы Ш.В.Низамиев